**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 сентябрендәге 3994 номерлы карары**

**«Казанга гашыйк бул»**
**иҗади проектлар конкурсын уздыру турында**

Халыкны шәһәрнең туристлык потенциалын күтәрүгә катнаштыру юлы белән, туристлык һәм мәдәният үзәге буларак, Казанга игътибар җәлеп итү, шулай ук эчке һәм читтән керү туризмын үстерү максатыннан **карар бирәм**:

1. «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенә (Д.А.Санникова) «Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсын оештыру, координацияләү һәм аны уздыруны контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүгә вәкаләтләр бирергә.

2. Расларга:

2.1. «Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсын уздыру тәртибе турында нигезләмәне әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә;

2.2. «Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсын уздыру буенча конкурс комиссиясе составын әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 28 мартындагы 901 номерлы «“Казанга гашыйк бул” видеороликлар конкурсын уздыру турында»гы карарын (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 25 апрелендәге 1169 номерлы, 2023 елның 27 июнендәге 1798 номерлы һәм 2023 елның 3 октябрендәге 2923 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 сентябрендәге
3994 номерлы карары белән
расланды

**«Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсын уздыру тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсын (алга таба – Конкурс) уздыру тәртибен җайга сала, аның максатларын һәм бурычларын, оештыру һәм уздыру вакытын, Конкурста катнашу шартларын һәм тәртибен, Конкурс нигезендә сайлап алу һәм анда җиңүчеләрне бүләкләү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Конкурсны оештыручы).

1.3. Номинациягә бәйле рәвештә Конкурста түбәндәге затлар катнаша ала:

- эшкә сәләтле балигъ булган физик зат яки 14 яшькә җиткән һәм аның исеменнән законлы вәкил эш йөртә торган физик зат;
- югарыда күрсәтелгән физик затлардан торган һәм аларның саны 5 кешедән артмаган команда.

1.4. Конкурсны оештыручы:

1.4.1. Конкурста катнашучыларның барысы өчен дә тигез шартлар булдыруны;

1.4.2. Конкурс уздыруның ачыклыгын;

1.4.3. Конкурс нәтиҗәләрен аларны рәсми рәвештә игълан итү көненнән иртәрәк хәбәр итүгә юл куймауны;

1.4.4. Конкурсның җиңүчеләре һәм призерлары дип танылган катнашучыларга бүләкләр тапшыруны тәэмин итә.

1.5. Әлеге нигезләмә кысаларында акчалата грант дигәндә Конкурсның җиңүчеләрен һәм призерларын әлеге нигезләмә белән билгеләнгән шартларда, категорияләрдә һәм күләмдә акчалата бүләкләү күздә тотыла.

## II. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

Конкурсның төп максатлары – халыкны шәһәрнең туристлык потенциалын күтәрүгә катнаштыру юлы белән, туристлык һәм мәдәният үзәге буларак, Казанга игътибар җәлеп итү, шулай ук эчке һәм читтән керү туризмын үстерү.

Конкурсның төп бурычлары:

- халыкны Казан шәһәренең туристлык потенциалын күтәрүгә җәлеп итү;
- халыкны территория брендын үстерүгә җәлеп итү, шулай ук патриотик тәрбия бирү;
- шәһәрнең иҗади потенциалын һәм мәдәни төрлелеген үстерүгә ярдәм итү;
- кунакчыллык индустриясен һәм туристлык инфраструктурасын алга таба үстерүдә ярдәм итү;
- туристларны җәлеп итә торган, шул исәптән кабат килү туризмын үстерү өчен истә калырлык чаралар һәм проектлар оештыру;
- Казан шәһәре брендын таныту эшен үстерү;
- потенциаль туристларның шәһәрнең туристлык мөмкинлекләре турындагы белемнәрен арттыру;
- шәһәр халкы һәм кунаклары арасында татар халкының мәдәни гореф-гадәтләрен популярлаштыру;
- җәмәгатьчелектә Казан шәһәре территориясе турында уңай фикер формалаштыру.

## III. Конкурс номинацияләре

Конкурс түбәндәге номинацияләрне үз эченә ала:

- «Казан турында иң яхшы видеоролик». Номинациядә Конкурста катнашучы аерым авторлар тарафыннан төшерелгән һәм монтажланган авторлык видеороликлары катнаша. Номинациядә катнашучы видеоролик Казанның төп туристлык потенциалын билгели торган урыннар, вакыйгалар, кешеләр яки объектлар турында мәгълүмат җиткерергә тиеш;
- «Казан турында иң яхшы видеоролик. Команда». Номинациядә Конкурста катнашучы гражданнарның иҗади берләшмәсе (команда) тарафыннан төшерелгән һәм монтажланган авторлык видеороликлары катнаша. Номинациядә катнашучы видеоролик Казанның төп туристлык потенциалын билгели торган урыннар, вакыйгалар, кешеләр яки объектлар турында мәгълүмат җиткерергә тиеш;

- «“Туристик Казан” темасына иң яхшы фотоэш». Номинациядә Казан шәһәренең күптөрлелеген һәм матурлыгын чагылдырган авторлык фотосурәтләре, панорама күренешләре катнаша. Кадрларда кешеләр яки хайваннар булу рөхсәт ителә, ләкин төп төшерү объекты сыйфатында түгел;

- «Казанда туризм турында иң яхшы мәкалә». Әлеге номинациядә катнашучыларга Казан шәһәрендә туризм темасын ачучы актуаль публицистик мәкалә язарга тәкъдим ителә. Шул ук вакытта нәкъ менә Казан шәһәренә сәяхәт итүнең өстенлекләре яктыртылырга һәм ачылырга тиеш. Мәсәлән, шәһәрнең бай һәм күптөрле гастрономик культурага ия булуы; шәһәрдә романтик урыннар булу; гаилә, балалар туризмы, мәдәни туризм, спорт, сәнәгать, су, хаҗ туризмы өчен мөмкинлекләр булу һәм башка тематика.

## IV. Конкурста катнашу өчен шартлар

4.1. Конкурста 14 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала.

4.1.1. «Казан турында иң яхшы видеоролик» номинациясенә, читтән ярдәм җәлеп итмичә, бер катнашучы – физик зат тарафыннан шәхсән башкарылган эшләр кертелә.

4.1.2. «Казан турында иң яхшы видеоролик. Команда» номинациясендә видеоролик төшерүгә җәлеп ителгән 5 тән артык булмаган сандагы кешедән торган команда катнаша. Команданың һәр катнашучысы турында мәгълүмат гаризада күрсәтелергә тиеш. Акчалата бүләк һәм диплом командага бирелә.

4.2. Конкурста катнашучы барлык номинацияләрдә дә катнаша ала. Шул ук вакытта берничә номинациядә катнашучы зат бары тик бер номинациядә генә җиңүче дип танылырга мөмкин.

4.3. Конкурста аны оештыручылар («Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләре), Конкурс комиссиясе әгъзалары катнаша алмый.

4.4. Конкурска тәкъдим ителә торган эшләр элек басылып чыкмаган булырга, авторлык характерында һәм Конкурс максатларына һәм бурычларына җавап бирә торган төгәлләнгән оригиналь әсәрләр булырга тиеш.

4.5. Интернет челтәрендә булган материалдан файдалану тыела.

4.6. Әлеге нигезләмә Конкурста катнашучылар белән Конкурс кысаларында җибәрелгән эшләргә интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсен файдалану хокукын бирү турында лицензия килешүе төзүгә ачык оферта булып тора.

Катнашучы интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсеннән файдалану хокукын бирү турындагы лицензия килешүе нигезендә Конкурсны оештыручыга, башка затларга бирү мөмкинлеге булган гади лицензия шартларында, интеллектуаль эшчәнлек объектыннан Россия территориясендә 49 (кырык тугыз) елга файдалану хокукын бирә.

Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре Конкурсны оештыручы тарафыннан Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 1270 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән файдаланылырга мөмкин.

Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсеннән файдалану хокукын бирү турында күрсәтелгән лицензия килешүе түләүсез булып тора, шул рәвешле эш авторына интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсеннән файдаланган өчен акча түләнми.

Конкурсны оештыручы һәм катнашучы арасында авторлык эшләренә интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсеннән файдалану хокукын бирү турындагы лицензия килешүе Конкурста катнашучы үз эшен www.yaratamkazan.ru сайтына йөкләгәннән соң төзелгән (Катнашучы тарафыннан акцептланган) дип санала, шул ук вакытта интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә карата кулланыла.

4.7. Конкурста катнашу өчен гаризаны, www.yaratamkazan.ru сайтында тутырып, 2025 елның 15 гыйнварына кадәр тапшыру зарур.

4.8. Гариза әлеге нигезләмәгә 1 номерлы кушымтада китерелгән формага туры килергә тиеш.

Команда номинациясендә катнашу өчен гариза, команданың барлык әгъзалары турында мәгълүматны күрсәтеп, команданың бер әгъзасы тарафыннан бирелә.

## V. Эшләргә карата таләпләр

5.1. Видеороликка карата таләпләр:

- видеоролик смартфонга да, профессиональ видеокамерага да төшерелергә мөмкин;
- бер катнашучыдан/автордан бер эш кенә кабул ителә;
- видеороликта әдәпсез сүзләр булырга тиеш түгел;
- видеоролик төшерү өчен киңәш ителә торган форматлар: mp4, mpeg, avi;
- якларның нисбәте – 16:9;
- видеоязмаларның дәвамлылыгы иң югары төгәллектә һәм иң яхшы сыйфатта 1 минуттан 5 минутка кадәр булырга тиеш;
- аудиокодек – MPEG Layer II яки Dolby AC-3;
- аудионың битрейты – 128 кбит/с яки югарырак;

- видеокодек – H.264;
- аудиокодек – AAC;
- аудиовизуаль фрагментның минималь дәвамлылыгы – 1 минут (видеода кара һәм статик сурәтләрне, шулай ук тавыш юлындагы тынлыкны һәм фон шау-шуын кертмичә);
- аудиовизуаль фрагментның максималь дәвамлылыгы – 5 минут;
- видеоның башлангыч ешлыгы секундына 24 тән 30 кадрга кадәр булырга тиеш;
- Конкурска реклама характерындагы, башка кешеләрнең абруен һәм хисләрен кимсетә торган, Конкурс тематикасына туры килми торган, кеше гомере өчен куркыныч шартларда төшерелгән, шулай ук авторлык хокукларын бозып әзерләнгән һәм элегрәк басылып чыккан роликлар кабул ителми;
- роликларда шәһәрнең тарихын, анда яшәүчеләрне, Казанда булып узган мөһим вакыйгаларны (сәяси контексттан тыш) искә алу; Казанның матур урыннарын күрсәтү; шәһәргә һәм аның халкына адресланган теләкләр һәм котлаулар булу хуплана;
- эш YouTube, RUTUBE видеохостингларында, «ВКонтакте» социаль челтәрендә һәм башка мәйданчыкларда #ВлюбисьвКазань2024 Конкурс хэштегы белән урнаштырылырга тиеш.

5.2. Фотографиягә карата таләпләр:

- эш смартфонга да, профессиональ фотокамерага да төшерелгән булырга мөмкин;
- фотоэшкә аны төшерү турында мәгълүмат (авторлык исеме, фотосурәттәге объектның тасвирламасы) теркәлергә тиеш;
- фотосурәтләр цифрлы форматта тапшырылырга тиеш;
- цифрлы файллар JPEG форматында булырга тиеш;
- сурәтнең размеры – озын ягы буенча 2 500 пиксельдән ким һәм 5 700 пиксельдән артык түгел;
- мобиль телефонга төшерелгән сурәтләр өчен сурәтнең размеры – озын ягы буенча 1000 пиксельдән ким һәм 5 700 пиксельдән артык түгел;
- Конкурс эшләрендә нинди дә булса авторлык яркалары, өстәлгән кысалар, су билгеләре, язулар (имзалар) һ.б. булырга тиеш түгел;
- эш #ВлюбисьвКазань2024 Конкурс хештегы белән «ВКонтакте» социаль челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

5.3. Мәкаләгә карата таләпләр:

- басма эш күләме буш аралар белән бергә кимендә 4 000 басма билгене тәшкил итәргә тиеш;

- материалда әдәпсез сүзләр булырга тиеш түгел;
- барлык материаллар да рус телендә бирелергә тиеш;
- эш текстында #ВлюбисьвКазань2024 дигән Конкурс хештегы кулланылырга тиеш;
- Конкурска реклама характерындагы, башка кешеләрнең абруен һәм хисләрен кимсетә торган, Конкурс тематикасына туры килми торган, шулай ук авторлык хокукларын бозып әзерләнгән һәм элегрәк басылып чыккан эшләр кабул ителми;
- эш #ВлюбисьвКазань2024 Конкурс хештегы белән «ВКонтакте» социаль челтәрендә, «Дзен» платформасында яки теләсә кайсы башка интернет-басмада урнаштырылырга тиеш.

## VI. Авторлык хокуклары

6.1. Конкурста катнаша торган эшкә карата авторлык хокукларын яклау өчен әлеге эшне юллаган автор җаваплы.

6.2. Эшләрнең авторлык хокукы Конкурста катнашучыныкы яки катнашучылар командасыныкы булырга тиеш.

6.3. Кирәк булган очракта, Конкурсны оештыручы автордан видеороликның төп нөсхәсен соратып алырга мөмкин.

6.4. Конкурста (эшне нигезләмәнең 4.7 пунктында билгеләнгән тәртиптә урнаштыру юлы белән) катнашырга теләк белдергән автор нигезләмәнең 4.6 пункты нигезендә Конкурсны үткәрү вакытында һәм ул тәмамлаганнан соң да эшне теләсә кайсы ысул белән, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, Конкурсны оештыручының интернет-платформаларында, социаль челтәрләрдә урнаштыру юлы белән; Конкурс эшләре турында халык алдында фикер алышуны оештыру максатыннан, күргәзмәләр һәм форумнар вакытында, шул исәптән белем бирү оешмаларында, китапханәләрдә җәмәгатьчелеккә күрсәтү юлы белән бастырып чыгарылырга һәм күрсәтелергә мөмкин булуы белән ризалаша.

## VII. Конкурс комиссиясе

7.1. Тапшырылган эшләрне карап тикшерү максатыннан Конкурсны оештыручы, Казан шәһәренең дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, туристлык бизнесы, иҗтимагый, уку-укыту оешмалары һәм фәнни оешмалар вәкилләреннән торган Конкурс комиссиясе төзелә.

7.2. Конкурс комиссиясе составына комиссия рәисе, секретарь һәм 10 комиссия әгъзасы керә.

7.2.1. Конкурс комиссиясе рәисе Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, шулай ук комиссия утырышларын үткәрү өчен җавап бирә.

7.2.2. Конкурс комиссиясе секретаре Конкурс комиссиясе эшен оештыруны, шул исәптән гаризалар исемлеген формалаштыруны, карарларны рәсмиләштерүне, комиссия утырышы беркетмәсен алып баруны тәэмин итә.

7.3. Конкурс комиссиясе составы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

7.4. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итү Конкурсны оештыручы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7.5. Конкурста катнашучыларны һәр номинация буенча бәяләү өчен Конкурс комиссиясе:

- гариза-анкеталарның әлеге нигезләмәнең V бүлеге белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә;
- бәяләү кәгазенең формасын раслый;
- һәр катнашучының эшен гадел бәяли;
- һәр катнашучының рейтингыннан чыгып, Конкурска йомгак ясый.

7.6. Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләрне ачыклау әлеге нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасында китерелгән бәяләү критерийлары буенча Конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7.7. Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләрне ачыклаганда тавышлар саны тигез булса, Конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

7.8. Конкурс комиссиясе үз көче белән һәм үз вәкаләтләре кысаларында тапшырылган материаллардагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә. Конкурста катнашу өчен бирелгән гаризада ялган яки дөрес булмаган белешмәләр, шулай ук гамәлдәге законнарга каршы килә торган мәгълүмат ачыкланган очракта, мондый гаризалар карап тикшерелми.

7.9. Конкурс комиссиясе әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, Конкурс комиссиясе утырышы башланганчы, бу хакта Конкурс комиссиясе рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы Конкурс комиссиясе утырышында катнашмый.

7.10. Конкурс комиссиясе утырышы, анда Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып

санала.

7.11. Конкурс комиссиясе карары катгый һәм үзгәртелми.

## VIII. Конкурсны уздыру һәм җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

8.1. Конкурс 2024 елның 16 сентябреннән 2025 елның 28 февраленә кадәр үткәрелә.

8.2. Конкурста катнашучыларның һәр номинация буенча һөнәри осталыгы дәрәҗәсен Конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү 2025 елның 15 гыйнварыннан 2025 елның 20 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла. Хөкемдарлык барышында шәхси кызыксыну очрагын булдырмас өчен номинациядә катнашучы һәр кеше буенча бәя коллегиаль рәвештә кабул ителә һәм, уртак фикер алышудан соң, бердәм ачык бәяләү кәгазенә куела.

8.3. Конкурс таләпләренә һәм шартларына туры килә торган катнашучылар, Конкурс комиссиясе тарафыннан эшләнгән бәяләү кәгазьләре нигезендә, Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 5 баллы шкала буенча бәяләнә.

8.4. Катнашучының рейтингы Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасына тигез.

8.5. Конкурс комиссиясенең Конкурска йомгак ясау турында карары күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан расланган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Конкурс комиссиясе әгъзасы, Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, беркетмәгә үзенең аерым фикерен кертә.

8.6. Конкурс комиссиясе утырышы 2025 елның 20 февраленнән дә соңга калмыйча уздырыла.

8.7. Конкурсны оештыручы барлык номинацияләр буенча Конкурс нәтиҗәләрен 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) бастырып чыгара.

## IX. Катнашучыларны бүләкләү

9.1. Конкурста һәр номинациядә өч җиңүче билгеләнә. Эшләре җиңүчеләр арасына эләкмәгән катнашучылар Конкурста катнашу турында грамоталар белән бүләкләнә.

9.2. Приз фонды:

1) Конкурста җиңүчеләр акчалата грант белән бүләкләнә:

- «Казан турында иң яхшы видеоролик. Команда» номинациясендә – 150 000 (йөз илле мең) сум;

- «Казан турында иң яхшы видеоролик» номинациясендә – 100 000 (йөз мең) сум;

- «“Туристик Казан” темасына иң яхшы фотоэш» һәм «Казанда туризм турында иң яхшы мәкалә» номинацияләрендә – 50 000 (илле мең) сум;

2) II урынга лаек булганнар өчен:

- «Казан турында иң яхшы видеоролик. Команда» номинациясендә – 100 000 (йөз мең) сум;

- «Казан турында иң яхшы видеоролик» номинациясендә – 50 000 (илле мең) сум;

- «“Туристик Казан” темасына иң яхшы фотоэш» һәм «Казанда туризм турында иң яхшы мәкалә» номинацияләрендә – 30 000 (утыз мең) сум;

3) III урынга лаек булганнар өчен:

- «Казан турында иң яхшы видеоролик. Команда» номинациясендә – 50 000 (илле мең) сум;

- «Казан турында иң яхшы видеоролик» номинациясендә – 30 000 (утыз мең) сум;

- «“Туристик Казан” темасына иң яхшы фотоэш» һәм «Казанда туризм турында иң яхшы мәкалә» номинацияләрендә – 15 000 (унбиш мең) сум.

9.3. Приз фонды суммалары физик затлар keremenә салымны тотып калып исәпләнгән һәм җиңүчеләргә түләү өчен ахыргы сумма булып тора.

9.4. Акчалата грант алу өчен Конкурста җиңгән катнашучы, шулай ук җиңүче команда составындагы һәр катнашучы, җиңүче дип танылган вакыттан башлап 3 (өч) айдан да соңга калмыйча, Конкурсны оештыручы белән zv.g@tatar.ru электрон почтасы аша элемтәгә чыгарга һәм акчалата грант алу өчен фамилиясен, исемен, атасының исемен, паспорт күчермәсен, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын, салым органында исәпкә куелу турындагы таныклык күчермәсен, кредит оешмасында ачылган счет реквизитлары турында белешмәләр күрсәтелгән акчалата грант күчерүгә гаризаны үз эченә алган мәгълүмат тапшырырга тиеш. Гариза Конкурста җиңүче тарафыннан имзалана.

9.5. Акчалата грант җиңүче команданың һәр әгъзасына, командадагы катнашучылар саныннан һәм акчалата грантның гомуми суммасыннан чыгып, пропорциональ рәвештә түләнә.

9.6. Конкурста җиңгән катнашучының, шулай ук җиңүче команда составындагы һәр катнашучының нәтиҗә игълан ителгәннән вакыттан алып 3 ай

вакыт эчендә акчалата грант таләп итмәве мондый җиңүчене акчалата грант алу хокукыннан мәхрүм итә.

9.7. Акчалата грант Конкурс үткәрүгә Конкурсны оештыручы белән түбәндәге конкурентлык процедурасы нигезендә контракт төзегән шәхси эшмәкәр Антонов Максим Юрьевич тарафыннан (ИНН 165120432690, Казан шәһәре, Четаев урамы, 107 йорт, 11 фатир) Конкурста җиңгән катнашучы мөрәҗәгать иткән көннән башлап 1 (бер) ай эчендә түләнә: Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган 0811303000083240005335 номерлы сатып алу кысаларында электрон формада котировкалар сорату (бастырып чыгару, электрон формада котировкалар соратып алуга хәбәрнамә датасы – 2024 елның 13 июне).

9.8. Җиңүче акчалата грант алудан баш тартуы турында белдерергә хокуклы. Мондый баш тарту катнашучы тарафыннан ирекле формада язылган һәм Конкурсны оештыручыга почта адресы буенча яки PDF-файл форматында zv.g@tatar.ru электрон почтасына җибәрелгән гаризасында күрсәтелергә тиеш.

9.9. Конкурста җиңүчеләргә бүләк акчасын түләүче оешма Россия Федерациясе Салым кодексының 24 статьясы нигезендә салым агенты булып тора һәм отыш суммасының 13 проценты күләмендә физик затлар кеременә салым түли.

---

«Казанга гашыйк бул»
иҗади проектлар конкурсын
уздыру тәртибе турында
нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**«Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсында катнашу өчен гариза-анкета**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| 2 | Туу датасы (көн, ай, ел) | |
| 3 | Элемтә өчен телефон номеры | |
| 4 | E-mail | |
| 5 | Эшнең исеме | |
| 6 | Номинация | |
| 7 | Эшкә/басмага сылтама | |

Искәрмә. Әлеге гаризаны тутырган катнашучы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирә.

«Казанга гашыйк бул»
иҗади проектлар конкурсын
уздыру тәртибе турында
нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**«Казан турында иң яхшы видеоролик» номинациясенә**
**тәкъдим ителгән эшне бәяләү кәгазе**

Эшнең исеме______________________________________________________

Авторы__________________________________________________________

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәя (1 дән 5 баллга кадәр) | Ачыклама |
|---|---|---|---|
| **Эчтәлеккә карата эксперт бәяләмәсе** | | | |
| 1 | Эшнең игълан ителгән темага туры килүе | | |
| 2 | Теманың нигезләнгән булуы һәм аны ачып бирү тирәнлеге, аныклыгы | | |
| 3 | Видеороликның креативлыгы (идеянең яңа һәм үзенчәлекле булуы, иҗади фикерләү сәләте) | | |
| 4 | Мәгълүматка бай булу | | |
| **Техникага карата эксперт бәяләмәсе** | | | |
| 1 | Видеоязманың сыйфаты | | |
| 2 | Махсус тәэсир итү чараларыннан файдалана белү дәрәҗәсе | | |
| 3 | Эшнең эстетик ягы | | |
| **Бәяләрнең йомгаклау суммасы** | | | |

Комиссия әгъзасы ____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Комиссия әгъзасы имзасы ______________________________________

Тутыру датасы _______________________________________________

**«Казанда туризм турында иң яхшы мәкалә» номинациясенә тәкъдим ителгән эшне бәяләү кәгазе**

Эшнең исеме______________________________________________

Авторы__________________________________________________

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәя (1 дән 5 баллга кадәр) | Ачыклама |
|---|---|---|---|
| **Эчтәлеккә карата эксперт бәяләмәсе** | | | |
| 1 | Эшнең игълан ителгән темага туры килүе | | |
| 2 | Теманың нигезләнгән булуы һәм аны ачып бирү тирәнлеге, аныклыгы | | |
| 3 | Креативлык (идеянең яңа һәм үзенчәлекле булуы, иҗади фикерләү сәләте) | | |
| 4 | Мәгълүматка бай булу | | |
| **Техникага карата эксперт бәяләмәсе** | | | |
| 1 | Текстның уникальлеге | | |
| 2 | Махсус тәэсир итү чараларыннан файдалана белү дәрәҗәсе | | |
| 3 | Сөйләм хаталары юк яки бер сөйләм хатасы җибәрелгән.<br>Текстның стиле күрсәтелгән максатчан аудиториягә һәм күрсәтелгән жанрга туры килә | | |
| 4 | Эшнең эстетиклыгы (мәкаләнең тексты бер бөтен, төп идеясе ачык, текст җанлы һәм истә калырлык итеп язылган, мәкаләнең композициясе һәм логик эзлеклелеге күзәтелә) | | |
| **Бәяләрнең йомгаклау суммасы** | | | |

Комиссия әгъзасы ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Комиссия әгъзасы имзасы __________________________________

Тутыру датасы ___________________________________________

**«“Туристик Казан” иң яхшы фотоэш» номинациясенә тәкъдим ителгән эшне бәяләү кәгазе**

Эшнең исеме________________________________________________

Авторы______________________________________________________

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәя (1 дән 5 баллга кадәр) | Ачыклама |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурс тематикасына туры килү | | |
| 2 | Теманы ачуга иҗади якын килү | | |
| 3 | Тәэсирле һәм үзенчәлекле автор алымы | | |
| 4 | Сәнгатьчә һәм эстетик яктан башкару дәрәҗәсе | | |
| 5 | Техник сыйфат | | |

Комиссия әгъзасы ___________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Комиссия әгъзасы имзасы ____________________________________

Тутыру датасы ______________________________________________

2 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 сентябрендәге
3994 номерлы карары белән
расланды

**«Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсын уздыру буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Санникова Дарья Александровна | конкурс комиссиясе рәисе, Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты директоры |
| Сәлмәнова Гүзәл Әсгать кызы | конкурс комиссиясе секретаре, Казан шәһәренең туризмны үстерү комитетының туристлык индустриясен үстерү бүлеге баш эксперты |
| Төхвәтуллина Илсөяр Мисхәт кызы | Казан шәһәренең баш архитекторы |
| Белицкая Жанна Владимировна | Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары – шәһәр дизайны бүлеге башлыгы |
| Абзалов Азат Искәндәр улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы |
| Казанцев Владимир Анатольевич | Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Исмаев Тимур Илдус улы | «Громкие рыбы» агентлыгының режиссеры һәм креатив продюсеры (килешү буенча) |
| Семененко Руслан Юрсановна | «Казань интересная» блогы авторы, Идел буе шәһәрләре ассоциациясе әгъзалары булып торган шәһәрләрнең туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Идел буеның кунакчыллык |

| | |
|---|---|
| | йолдызлары – 2022» I һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы сити-блогер» номинациясе җиңүчесе (килешү буенча) |
| Яковлева Татьяна Павловна | «Бибрайт Ивент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте компаниясе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сафронов Александр Владимирович | тревел-фотограф (килешү буенча) |
| Маевский Кирилл Юрьевич | «Смена» заманча мәдәният һәм китап кибете үзәгенә нигез салучыларның берсе һәм программа директоры, «Смена»ның җәйге китап фестивале программа директоры, Ad Marginem нәшриятының башкарма директоры, Вознесенский үзәге кураторы (килешү буенча) |
| Шакиров Альфред Илдар улы | Казан федераль университетына караган Социаль-философия фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтының милли һәм глобаль медиа кафедрасы доценты (килешү буенча) |

______________________